РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06.08.2021

№ 948-п

Объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына техник регламентлары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында, биналарны, корылмаларны карауны уздыру комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Саба муниципаль районы Советының “Объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына техник регламентлары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында, биналарны, корылмаларны карауны уздыру комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2015 елның 10 сентябрендәге 319 номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына техник регламентлары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында, биналарны, корылмаларны карауны уздыру комиссиясе төзү турында”гы 2020 елның 7 июлендәге N899-п номерлы карары белән расланган, объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына техник регламентлары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның

техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында, биналарны, корылмаларны карауны уздыру комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктта түбәндәге эчтәлекле 4.1.1 пунктчасы өстәргә:

“4.1.1. объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына техник регламентлары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп, аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында, биналарны, корылмаларны карауны уздыру комиссиясе утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы булып санала.”.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов